**1917-1930 еллар**

Яңа программа белән укыту.

1917-18 елларда яңача укыту өчен Нарат авылы кешесе Гобәйдуллин Касыйм, аның хатыны Әсма килә. Шуннан соң кыз һәм ир балаларны бергә укыта башлыйлар. Касыйм Гобәйдуллин һәм аның хатыны революцион фикерле коммунистлар булалар, һәр эштә актив катнашалар, авылда культура эшен үстерергә тырышалар.

1919 ел. Яз. Бу вакытта безнең тирәләргә Колчак армиясе басып килә. Шуңа күрә аларны дошманга каршы сугыш өчен татар полкына оештыру эшләренә Казанга чакыралар. Аңа ияреп Наратның бай малае Минһәҗов Габденур да атасы ризасызлыгына карамастан :"Без кайтып сезнең байлыкларыгызны туздырып, байлыгыгызның алып китәрбез әле ",- дип Касыйм белән Әгерҗегә китәләр, ләкин Казанга баручы аерым эшелонга өлгерә алмыйлар һәм кире авылга кайтырга чыгалар. Юл өзеге, пычрак вакыт була. Нарат, Эсләк тирәсендә булып үткән Колчак солдатлары Әгерҗегә таба баралар. Бу вакытта Илдебай урманы юлы өстендә Касыйм һәм Минһаҗев Габденур Колчак армиясенә очрап, кача алмыйлар. Аларның кемнәр булуын Нарат авылының Колчак армиясен озата баручылар әләклиләр.Шул вакытта аларны Илдебай урманы янында атып үтерәләр.

Кадыбашта болардан башка тагын күп кенә укытучы хатын-кызлар булып китәләр. Мәсәлән: Казанцева Зөһрә, Буби авылыннан Арсланова Хәҗәр, Салагыштан Хәят..

1924-1925 елда Исәнбайдан Җәмилев Шамил укыта



1926 нчы елда Касайдан Яппаров Габдулла (элеккеге мулла малае) Кадыбашка мәктәп мөдире булып килә.. Ул "Терәк-үрнәк мәктәп" дип йөртелә. 1930 нчы елдан авылда җидееллык гомуми мәҗбүри уку кертелә. 4 нче классны тәмамлаган балалар 1930-1931 нче елларда Исәнбайга, 1932-1933 нче елларда Девятерняга укырга йөри башлыйлар. Анда урта мәктәп була.

Яппаров Габдулла 1896 нчы елда Касай авылында мулла гаиләсендә туган. Иж Бубый урта мәктәбен тәмамлый. Урта белемле мулла булып чыккан кеше. Ул Кадыбышта эшләү дәверендә бик нык оештыручы, яшьләрне тәрбияләү, спектакльләр кую, колхозлар оештыруда, укыту-тәрбия эшләрен яхшыртуда зур көч куя. Авылда яңа, заманча итеп мәктәп салуда чикләнмәгән зур хезмәтен куйган.

Касай авылында эшләгәндә, 1919 нчы елның язында, Колчак армиясе үткәндә, Яппаров Габдулла абыйны авыл уртасындагы күпер янына атарга китерәләр һәм мылтыкларын төбиләр. Ләкин Фәтхетдинов Низам картның халыкка булган мөрәҗәгате-соравы нәтиҗәсендә барлык авыл халкы аны атмауны сорыйлар. Аны атмый калдырып, 30 шомпол белән алмаштыралар һәм аны каты кыйнап китәләр. Яппаров ,моннан савыккач ,тагын да ныграк советчыл фикерле кешегә әйләнә. 1929-1936 нчы елларда аның белән Халиков, Камалетдинова Маугыйдә дигән укытучылар авылда барлык культура, коллективлашу эшләрендә актив катнашалар,яшьләр белән бергә эшлиләр.

Авылда беренче спектакль 1926 нчы елда хәзерге авыл советы бинасы урынында ике катлы бай йортында куела. Беренче пьеса "Ураза бәйрәмендә бал тәпәне" дип атала. Бу 1 май бәйрәме көнне була, ләкин яшьләр спектакльне куеп бетерә алмыйлар. Кулаклар ике-өч тапкыр кереп утларын сүндереп, үзләрен кыйнарга йөриләр,ләкин артистлар качарга өлгерәләр. Спектакль куюда Яппаров Г, Рашитов Н, Сибатов С, Рахмаев Г, Яппаров Ә, Кадыйров С. Һәм башкалар катнашалар. Спектакльне икенче көнне ике милиция карап торып куйдыралар.